«ПРОЕКТ»

РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.08.2021 с. Сарманово № 226

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
башкарма комитетының
муниципаль хезмәт күрсәтү
административ регламентларын
раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләре, хезмәтләр күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карарын үтәү өчен КАРАР ИТӘМ:

1. Расларга:

1.1. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2 Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган сүтү һәм капиталь төзелеш объектын сүтеп бетерү турында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими пассажирлар йөртү маршруты карталарын рәсмиләштерү, даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкларны һәм даими пассажирлар йөртү маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).